**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**11 август 2020 ел** **№ 171**

**Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.5 статьясына, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә, Красносельский авыл җирлеге Советының 2009 елның 21 октябрендәге 142 номерлы карары (2009 елның 26 декабрендәге 157 номерлы редакциясендә) белән расланган Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенә, Красносельский авыл җирлеге Уставына таянып, Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Җирләүгә тарифлар билгеләү, җирләү һәм җирләү эше өлкәсендә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешендә ритуаль хезмәтләр оештыру буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшырырга.

2. Әлеге карарны карау өчен Биектау муниципаль районы Советына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (Газизов Илдар Зөфәр улы) Биектау муниципаль районы Советы карары кабул ителгәннән соң 10 календарь көннән дә артмаган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы килешү төзүдә як булырга.

4. Әлеге карарны интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адрес буенча «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Красносельский авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Газизов И.З. йөкләргә.

Совет рәисе
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин